ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

31.03.2023 Баулы шәһәре №85

Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының «Җир кишәрлеген алдан килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 30 июлендәге 139 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Җир кодексына һәм «Россия Федерациясе Җир кодексын гамәлгә кертү турында» Федераль законның 3.5 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 5 декабрендәге 509 номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының «Җир кишәрлеген алдан килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 30 июлендәге 139 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләрне кертергә:

преамбулада «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы карары белән» сүзләрен төшереп калдырырга;

Административ регламентта (карарга кушымта):

1 нче «Гомуми нигезләмәләр» бүлегендә:

түбәндәге эчтәлекле 1.6. пункт өстәргә:

«1.6. Муниципаль хезмәтне алдан ук (проактив) режимда күрсәтү каралмаган.»;

2 нче «Муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты» бүлегендә:

2.4.1. пунктның 4 абзацында «кырык биш көн» сүзләрен «утыз биш көн» сүзләренә алмаштырырга;

2.6.1. пунктның 8) пунктчасында «Россия Федерациясе пенсия фонды» сүзләрен «Россия Федерациясе пенсия һәм социаль иминләштерү фонды» сүзләренә алмаштырырга;

2.8.3.2 пунктның 13) пунктчасында «бакчачылыкны» сүзен «гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылыкны алып барулары» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Баулы муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең игъдисади үсеш буенча урынбасарына йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Л. Бакиров